## Уңай Ризалык Билгеләмәсе

Уңай ризалык - ул барлык әгъзалар арасындагы ирекле, җенси мөнәсәбәттә катнашу өчен үзара карары. Ризалык сүз яки хәрәкәт белән бирелергә мөмкин, бу сүзләр яки хәрәкәтләр җенси мөнәсәбәткә әзер булу турында төгәл ризалык тасвирлаганга кадәр. Тынлык яки каршылык күрсәтмәү ризалык бирүне аңлатмый. Ризалык билгеләмәсе әгъзаның җенесе, сексуаль ориентациясе, гендер тәнгәллек яки гендер чагылышына бәйле түгел.

Нинди дә булса җенси мөнәсәбәткә ризалык яки моңа кадәр үзара яки төрле як белән алдан килешеп эшләнгән җенси мөнәсәбәт бүтән төрле җенси мөнәсәбәткә мәҗбүр итә алмый.

Башлап җибәрүче нинди хәлдә булса да, алкоголь һәм/яки наркотик йогынтысында булса да, ризалык алырга һичшиксез кирәк.

Ризалык алдан бирелергә мөмкин, яки төрле вакытта аннан баш тартырга мөмкин.

Кеше сафтан чыгарылган хәлдә булса, андый вакытта кеше аңлы рәвештә җенси мөнәсәбәткә керергә ризалыгы турында карар кабул итәргә сәләтле түгел, шуңа күрә ризалык бирелә алмый. Сафтан чыгу кешенең аңын югалту яки аның йоклавы белән, яки аның ирексездән тотылуына бәйле буырга мөмкин, яки әгәр кеше бүтәнчә ризалыгын белдерә алмаса. Алкоголь, наркотик яки бүтән төрле исертүче матдәләр йогынтысында кемнең дә булса исерү дәрәҗәсенә карап кеше сафтан чыгарылган булырга мөмкин, һәм шуңа күрә ул ризалыгын белдерә алмаслык хәлдә була.

Мәҗбүр итү, куркыту, көч кую яки зарар китерү куркынычы нәтиҗәсендә ризалык бирелергә мөмкин түгел.

Ризалык кире алынса яки яңадан бирелә алмаса, җенси мөнәсәбәт туктатылырга тиеш.

## Наркотиклар һәм Алкоголь Куллануда Гаепләнү очрагында Амнистия.

Rockland Community College студентының сәламәтлеге һәм куркынычсызлыгы иң мөһиме. RCC таный, эчкән һәм/яки наркотиклар кулланган (ирекле яки ихтиярсыз куллану) вакытта булган җәбер, алар арасында  гаиләдә ирексезләү, очрашу булганда көчләү һәм әзәрлекләү яки сексуаль көчләү, турында хәбәр итмәскә мөмкиннәр, аларның үз тотышлары турындагы нәтиҗәләрдән куркып. RCC студентларын  гаиләдә ирексезләү, очрашу булганда көчләү һәм әзәрлекләү яки сексуаль көчләү турында учреждение хезмәткәрләренә хәбәр итергә өнди.  RCC 'ка кагылган төрле гаиләдәге ирексезләү, очрашу булганда көчләү һәм әзәрлекләү яки сексуаль көчләү турында түрәгә яки тәртип саклаучыга хәбәр иткән намуслы кеше яки намуслы шаһит гаиләдәге ирексезләү, очрашу булганда көчләү һәм әзәрлекләү яки сексуаль көчләү вакытында яки шул тирәдә булганда RCC's кагыйдәләре буенча алкоголь һәм/яки наркотиклар куллану белән үз тотышы нормаларын бозса да җәзага дучар ителмиячәк.

## Студетлар Хокукы турында Билль

Бөтен студентларның түбәндәгегә хокуклары бар:

Җирле хокук саклау органнарына һәм/яки урынлы полициягә хәбәр бирү;

Гаиләдә ирексезләү, очрашу булганда көчләү һәм әзәрлекләү яки сексуаль көчләү кебек очракларга җитди карарга;

Җинаять яки тәртип бозу турында  хәбәр итү турында карар кабул итергә һәм, оешма ягыннан булган басымнан азат рәвештә, суд эше яки тикшерүдә һәм/яки җинаять эше процессында катнашу турында карар кабул итергә;

Гадел һәм сезне ишетү мөмкинлегенә ия булган тиешле рәвештә игътибар белән тәэмин иткән процесста катнашу;

Сыйфатлы дәрәҗәдә дәваланырга һәм учреждениядән ихтирамлы, гадел һәм хөрмәт белән мөмкин булган җирдә тиешле хезмәтләргә;

Хәбәр итүче кеше гаепле булу мөмкинлегеннән азат була, җинаять яки тәртип бозу булганнан соң, яки җинаятьне яки тәртип бозуны булдырмау өчен сез бүтән ысул белән эш итергә тиешле булгансыз дип уйлаганда;

Инцидентны берничә инстуциональ вәкил өчен сыйфатлау, инцидентны яңадан кабатларга туры килмәсен өчен.

Учреждение юрисдикциясе астында булучы төрле студент, гаепләнүче һәм/яки җавап бирүче, һәм/яки аларның дуслары, гайләләре һәм танышлары учреждение җәзасыннан сакланырга;

Билгеләмәне беренче дәрәҗәдә шикаять бирү мөмкинлеге;

Киңәш бирүче ярдәме белән кулланырга, ул җавап бирүчегә, гаепләнүчегә киңәшләр бирә һәм ярдәм күрсәтә бөтен суд процессы дәвамында һәм бу процесс белән бәйле төрле очрашулар һәм тыңлаулар дәвамында;

Гражданлык хокукын һәм дин гамәлләрен үтәүне тикшерү, җинаять яки суд эше яки процессны алып баручы учреждения ягыннан катнашу басымысыз.

Раса, тән төсе, милләт, дин, яшь, инвалид булу, җенес, сексуаль ориентация, гаилә хәле, балага узганлык, генетик сыйфатлама, хәрби статус, гаиләдә ирексезләү корбаны булу, яки хөкемгә тартылган булу, һәм җинаятьнең яки тәртип бозуның кампус эчендә, кампус читләреннән тыш яки чит илдә уку вакытында булуга карамастан хокуклар саклана.

Сез Кампус Полициясенә яки Кампус Куркынычсызлыгына, җирле тәртип саклаучыларына һәм/яки Дәүләт полициясенә гариза бирә аласыз яки хәбәр итмәскә дигән карар кабул итә аласыз; инцидент турында сезнең учреждениягә хәбәр итә аласыз; инцидент турында хәбәр бирү нәтиҗәсендә учреждение белән җәзадан сакланып кала аласыз; һәм сезнең учреждениедән ярдәм һәм ресурслар кабул итергә хокукыгыз бар.